ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**“ 26 ” октябрь 2020 ел** **№ 828**

**Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 1102 номерлы «2020-2022 елларга Арча муниципаль районының яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 1102 номерлы «2020-2022 елларга Арча муниципаль районының яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Арча муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 16 декабрендәге 1102 номерлы «2020-2022 елларга Арча муниципаль районының яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карары белән расланган «2020 - 2022 елларга Арча муниципаль районының яшьләр сәясәтен үстерү» муниципаль программасын кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Т.Мөхәммәтшина

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
«26» октябрь 2020 ел, № 828
карарына кушымта

**«2020-2023 елларга Арча муниципаль районы яшьләр сәясәтен үстерү»**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

**ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | «2020-2023 елларга Арча муниципаль районы яшьләр сәясәтен үстерү» (алга таба - Программа) |
| **Программаның заказчысы** | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты |
| **Программаны төп әзерләүче** | Арча районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| **Программының максаты** | Яшьләрнең социаль үсеше белән идарә итү, районның конкурентлык сәләтен ныгытуда аның иҗади потенциалыннан файдалану, социаль-икътисадый, оештыру, хокукый шартлар булдыру юлы белән яшь буынның яшәеш сыйфатын яхшырту һәм яшьләрнең потенциалын җәмгыять һәм дәүләт мәнфәгатьләрендә үстерү өчен уңайлы шартлар тәэмин итү |
| **Программының бурычлары** | 1. Татарстан Республикасы яшьләр сәясәтенең норматив-хокукый базасын Арча муниципаль районына җайлаштыру;<br>2. Яшьләрнең үзоешканлыгын үстерү максатларында яшьләрнең яңача һәм эшкуарлык эшчәнлеген |

| | |
|---|---|
| | координацияләү;<br>3.Яшьләрне үзоешуның төрле формалары белән кызыксындыру;<br>4.Яшьләр арасында тискәре күренешләрне кисәтү;<br>5. Яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен алга сөрү;<br>6. Яшьләргә гражданлык - патриотик тәрбия бирү;<br>7.Яшьләрдә гаилә кыйммәтләрен һәм социаль кыйммәтләрне формалаштыру;<br>8.Яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче органнарны һәм оешмаларны фәнни-методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне камилләштерү;<br>9.Яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче оешмалар эшчәнлеген координацияләү;<br>10.Яшьләрне үзоешуның төрле формалары белән кызыксындыру;<br>11.Яшьләрнең үз-үзләрен үстерү өчен шартлар тудыру, сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү;<br>12.Туризм үсешенә максатчан юнәлеш бирү. |
| **Подпрограмманы гамәлгә ашыру вакыты** | 2020 - 2023 еллар |
| **Программаны гамәлгә ашыруның төп этаплары исемлеге** | Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанслар бүлеге, Арча муниципаль районы башкарма комитетының «Мәдәният идарәсе» МУ, Арча муниципаль районы башкарма |

| | |
|---|---|
| | комитетының «Мәгариф идарәсе» МУ, КДН. |
| **Программаны финанслау күләмнәре** | 2020 - 2023 еллар – ел саен 1573,9 мең сум;<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Арча муниципаль районы Советы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. |
| **Озак вакытлы максатчан Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре** | - 14-30 яшьтәге гражданнарның иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә җәлеп ителгән яшьләр санын 20 %ка кадәр арттыру;<br>-Яшьләрнең гражданлык һәм патриотик дөньяга карашын формалаштыру юлы белән иҗтимагый һәм иҗади активлыгын үстерү;<br>-Яшьләрнең ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеге активлыгын стимуллаштыру;<br>-Яшьләр сәясәте өлкәсендә, органнар һәм оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылучы талантлы яшьләргә ярдәм итү проектларында һәм программаларында катнашучы яшь кешеләрнең өлешен яшьләрнең гомуми санынннан 25 % ка кадәр арттыру;<br>-Яшьләрдә кече һәм урта бизнес секторын үстерүгә юнәлтелгән тормышта үзләренә урын табуга омтылышлар формалаштыру;<br>-Яшьләр сәясәте һәм спорт учреждениеләрендә даими нигездә шөгыльләнүче авыр тормыш хәлендә калган балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр санын арттыру;<br>-Җәйге сәламәтләндерү ялының төрле формаларына җәлеп ителгән балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр санын арттыру; |

| | |
|---|---|
| | -Яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче гаиләләргә, балаларга һәм яшьләргә социаль - психологик ярдәм учреждениеләре эшчәнлеген үстерү;<br>-Яшүсмерләр һәм яшьләр арасында хокук бозулар һәм җинаятьләр санын киметү |

## 1. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЛКӘСЕНЕҢ ГОМУМИ ТАСВИРЛАМАСЫ, ШУЛ ИСӘПТӘН ПРОГРАММА ХӘЛ ИТҮГӘ ЮНӘЛТЕЛГӘН ПРОБЛЕМАЛАР

Арча муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәте стратегик мәсьәләләр рәтенә керә һәм яшьләрнең социальләшүе һәм тормышта үз урыннарын табуга, аның потенциалын үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлтелгән үсеш чаралары системасы булып тора; Яшьләр үзәкләре, Студентлар хезмәт отрядлары үзәге, "Патриот" республика спорт-патриотик үзәге, "Форпост" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) берләшмәләре үзәге, "Җәй" балалар һәм яшүсмерләрнең ялын һәм мәшгульлеген оештыру буенча республика үзәге, "Йолдызлык" сәләтле балалар белән эшләү республика үзәге кебек республика күләмендәге яшьләр оешмаларының тәҗрибәсен һәм яңа идеяләрен өйрәнү юлы белән тормышка ашырыла. Шуңа күрә районда яшьләр юнәлешен үстерү өлкәсендә конструктив һәм эзлекле хәрәкәт бары тик әлеге яшьләр учреждениеләре белән тыгыз элемтәдә генә булырга мөмкин.

Дәүләт һәм яшьләр мөнәсәбәтләрен җайга салучы заманча хокукый база нигезендә дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекләре билгеләнде. Иң мөһимнәре: "Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында" 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы, "Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында" 1999 елның 21 октябрендәге, "Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2006 елның 7

апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары.

Тармакара өлкә буларак дәүләт яшьләр сәясәте үзенчәлекләреннән чыгып, яшьләр проблемаларының бөтен спектры: белем бирү, эшкә урнаштыру, ялларын оештыру, социаль-тискәре күренешләрне кисәтү буенча ведомствоара координацияне ныгыту буенча яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, барыннан да элек, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү, социаль яклау, эчке эшләр органнары һәм башкалар белән үзара хезмәттәшлектә хәл итәргә тиеш.

2019 ел башына Арча муниципаль районында 51832 кеше яши. Шуның 22270е - яшьләр.

Муниципаль яшьләр чараларында һәм конкурсларында катнашучыларның төп өлеше муниципалитетның белем бирү оешмаларында укучылар, яшь укытучылар, укучыларның ата-аналары. Уртача алганда, муниципаль чараларда һәм акцияләрдә, шул исәптән хәрби-патриотик юнәлештәге акцияләрдә, агымдагы елда ике меңгә якын кеше катнашты.

Районның муниципаль спорт чараларында даими катнашкан яшьләр активы 14 яшьтән алып 30 яшькә кадәрге яшьләр, волонтерлар хәрәкәтендә катнашучылар, форпостчылар, яшь гвардиячеләр һәм яшь армиячеләр.

Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге имин булмаган гаиләләргә шефлык алып бара (Иске Масра авылы) һәм, кирәк булганда, туган проблемаларны хәл итүдә ярдәм итә.

Моннан тыш, ел саен “Җиңү көне”, “Балаларны яклау көне”, “Россия көне”, Бөек Ватан сугышы башлануга багышланган “Хәтер яктысы”, “Бөтендөнья татар яшьләре форумы”, “Тукай FEST”, “Тукай юлы” (Түбән Мәтәскә - Яңа Кырлай) маршрутын узу, “ Әйдә Районга” студент яшьләр форумы, “Игелекле торна” хәйрия фестивале, “Физкультурачы көне”,"Киртәләр аша йөгерү. Иң көчлеләр ярышы”, “Велотөн”, “Туплы Тамаша”, “Автобус 14:30” “Республика көне”, “Яшел Фитнес”, “Скейтбординг буенча Татарстан беренчелеге”, “PRO - хәрәкәт”, “Милли кросс”, “Сәламәтлек спартакиадасы” мәдәни-спорт чаралары, язгы һәм көзге кыр эшләре вакытында “Яшь

комбайнчыларны хөрмәтләү", "Чаңгыроллерлар буенча чемпионат", "Акыл батл", "Итекле хоккей", "Тукай SKI марафон", боз сараенда "Ак Барс командасы уенчылары белән яшь хоккейчылар очрашуы", "Россиянең чаңгы юллары", "Кышкы спартакиада" кебек масштаблы муниципаль чаралар үткәрелә.

Шулай ук, яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге районндагы "КВН" хәрәкәтләренә актив рәвештә ярдәм итә.

ГХАТ органы "Бердәм Россия" партиясе бүлекчәсе белән берлектә 14 яшькә җиткәннәргә тантаналы рәвештә паспорт тапшыра. Яшьләр РФ гражданы хокуклары һәм бурычлары белән таныша, патриотик тәрбия дәресе ала.

Арча муниципаль районында 2007 елдан "ФОРПОСТ" җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр берләшмәләре үзәге эшли. Үзәкнең төп максаты - яшүсмерләрнең социаль булмаган тәртибен булдырмау, наркомания, күзәтүчесез калуны һәм хокук бозуларны кисәтү, югары мәдәниятле гражданнар, әхлакый рухлы, спорт белән мавыгучан, инициативалы, мөстәкыйль, җәмгыятьтә үз урынын табарга сәләтле кешеләр тәрбияләү. Әлеге максатка ирешү өчен яшьләр белән төркемнәрдә һәм шәхсән физик, әхлакый һәм патриотик тәрбия эше алып барыла.

Үзәктә барлыгы 36 отряд исәпләнә. Аларның утыз икесендә мәктәп укучылары, өчесендә студентлар, берсендә яшьләр. Барлыгы - 323 кеше.

"Социаль тискәре күренешләрне булдырмау" юнәлеше буенча "ФОРПОСТ" үзәге хезмәткәрләре эчтәлекле ял оештыру, наркотикларга каршы акцияләр, районның авыл җирлекләре яшьләре белән очрашулар, яшьләр арасында наркомания, алкоголизм, тәмәке тарту кебек социаль тискәре күренешләрне булдырмауга юнәлтелгән әңгәмәләр, анкета тутыру кебек чаралар үткәрәләр. Шундыйлардан: «Сәламәтлек көне», «Аек көн», «Наркотикларга юк», «Терроризмга һәм экстремизмга юк», «Патриотлар үстерәбез» кебек чаралар үткәрелә.

Яшүсмерләр арасында тискәре күренешләрне булдырмау кысаларында яшүсмерләр спорт секцияләренә (көрәш, баскетбол, армрестлинг, футбол,

бадминтон) йөриләр. Үсмерләр шулай ук район күләмендәге мәдәни-массакүләм һәм спорт чараларын уздыруга җәлеп ителгән.

2019 елның октябреннән Арча районында Волонтерлык үзәге эшли башлады, анда 3 урта уку йортлары волонтёрлык отрядлары, шулай ук мәктәп волонтер отрядлары әгъзалары керде. Хәзерге вакытта Арча районының 35 мәктәбендә волонтерлык отрядлары белән эш алып барыла. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының "Мәрхәмәтлелек үзәге" халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәге базасында "Арча" волонтерлык отряды эшли. Патриотик юнәлешле чараларның күпчелек өлеше аларның инициативасы һәм ярдәме белән үткәрелә. Болар – дан аллеясын, истәлекле урыннарны һәм хәрбиләрне җирләгән урыннарны, обелиск территориясен җыештыру, шулай ук "Җиңү агачы" район акциясе, "Георгий тасмасы", "Үлемсез полк", "Хәтер яктысы" акцияләре. Инвалидлар үнкөнлеге кысаларында өйдән чыга алмаган балалар янына баралар. Аралашу әңгәмә, төрле уеннар, иҗат минутлары рәвешендә уза.

Моннан тыш, ел саен 15 майдан 15 сентябрьгә кадәр «Волонтерлар-балаларга» район акциясе, шулай ук «Көзге игелек атнасы» үткәрелә, аның кысаларында ихтыярлылар (доброволецлар) оешмалары әгъзалары авыр тормыш хәлендә калган мохтаҗларга һәм балаларга ярдәм итәләр.

Арча укучылар сараенда: "Балалар оешмалары советы - БОС" һәм "21 гасыр яшьләре" үз эшчәнлекләрен алып баралар.

Арча муниципаль районының Яшьләр үзәге формалашу һәм эшчәнлеккә әзерлек стадиясендә, аның эшчәнлеген түбәндәге юнәлешләр буенча алып бару планлаштырыла:

-Гражданлык-патриотик тәрбия

- Шәхеснең иҗади үсеше

-Белем бирү эшчәнлеге

- Мәдәни-тарихи, туган якны өйрәнү тәрбиясе

- Гаиләгә ярдәм һәм психология үзәге

Арча муниципаль районы Советы каршында яшьләрнең җәмгыятьнең сәяси тормышында катнашуына ярдәм итүче Яшьләр парламенты эшли.

Хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр һәм хәрби хезмәткә чакырылу яшендәге яшьләр белән эш дәвам итә. Ел саен район хәрби комиссариаты, мәгариф бүлеге белән берлектә, хәрби хезмәткә чакырылучы яшьләр өчен кыр-өйрәнү җыеннары үткәрелә, аларда физик әзерлек дәрәҗәсе тикшерелә. "Аҗаган" хәрби-спорт уены, хәрби-гамәли спорт төрләре буенча спартакиада үткәрелә.

Районда «Татарстан Республикасы Аграр яшьләр берләшмәсе» республика иҗтимагый оешмасының Арча бүлекчәсе эшли, ул авыл яшьләре мәнфәгатьләрен һәм омтылышын чагылдыра. Һәр авыл җирлегендә лидер эшли.

Аграр яшьләр берләшмәсе Советында 25 кеше. Авыл яшьләре белән җәйге чорда балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча ишегалды чаралары уздырыла. «Сельские вечера - Авыл кичләре» яшьләр кичәләре оештыру. Фестивальләр һәм "КВН".

2005 елдан “Бердәм Россиянең Яшь гвардиясе” Арча бүлекчәсе эшли. Катнашучылар саны - якынча 400 кеше.

Еллар узу белән сәләтле яшьләрне эзләү, аларга ярдәм итү һәм үстерү, конкурслар һәм фестивальләр оештыру системасы барлыкка килде. «Йолдызлык», «Алтын каләм», «Безнен заман» яшьләр фестивальләре традициягә әйләнде. Сәнгать коллективларының үзешчән эшчәнлеге смотрлары; нәфис сүз осталары конкурслары; үзешчән рәссамнар һәм декоратив сәнгать осталары күргәзмәләре. Ел саен авыл хуҗалыгының яшь хезмәткәрләре һәм башка эшче һөнәрләре арасында «Һөнәре буенча иң яхшы» конкурсы уздырыла.

Ел саен район яшьләре форумнарда, семинарларда һәм сораштыруларда катнашу мөмкинлеге бирә торган “Россия яшьләре” АИС порталында теркәлә. Бу районда дәүләт яшләр сәясәте үсешенә ярдәм итә.

Безнең районда физик культура һәм спортны алга сөрүгә зур игътибар бирелә. “Арча” һәм “Арча-арена” спорт комплексларында, гомуми белем бирү

учреждениеләрендә, район предприятиеләрендә һәм оешмаларында сәламәтлек почмаклары, спорт тормышы турында күргәзмә стендлар бар, “Без сәламәт яшәү рәвеше өчен!” девизы астында район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре арасында спортның төрле төрләре буенча спорт чаралары үткәрелә.

Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре тарафыннан яшүсмерләрне һәм яшьләрне спорт төрләре белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча актив эш алып барыла. Футбол, хоккей, өстәл теннисы, милли көрәш, волейбол, йөзү һ.б. секцияләр эшли.

Кышкы каникул чорында сәламәт яшәү рәвешен алга сөрү, балаларны һәм яшүсмерләрне мәшгуль итү максатыннан һәм укудан буш вакытта хоккей, волейбол, мини-футбол, бадминтон буенча иптәшләрчә очрашулар үткәрелә.

“Арча муниципаль районы” муниципаль берәмлеге сайтында, “Арча” балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, “Арча-арена”, “Укучылар сарае” сайтларында, шулай ук социаль челтәрләрдә мәгълүмати материаллар урнаштырыла: яшьләр тормышыннан яңалыклар тасмасы, фото һәм видеоматериаллар даими яңартыла. Сайтларга көн саен 150-200 кеше керә.

«Физкультурачы көненә» багышланган спорт бәйрәмен уздырганда иң яхшы спортчыларны һәм спорт хезмәткәрләрен бүләкләү традициягә әйләнде. Мәдәният бүлеге һәм район волонтерлары белән берлектә ел саен сәламәт яшәү рәвеше файдасына акцияләр уздырыла. Спорт хезмәткәрләре, спорт осталары һәм спорт ветераннары тарафыннан ел саен балалар бакчаларында һәм гомуми белем бирү мәктәпләрендә сәламәтлек дәресләре үткәрелә.

«2020-2022 елларга Арча муниципаль районында яшьләр сәясәтен үстерү» максатчан муниципаль программаны гамәлгә ашыру муниципалитетта яшьләр белән эшләү традицияләрен дәвам итәчәк һәм районның яшь кешеләрен акыллы, иҗади һәм физик яктан үстерү өчен яшьләрнең талантларын иртә ачу һәм аларга ярдәм итү өчен, аларның гражданлык һәм әхлакый тотрыклылыгын формалаштыру өчен, эшчәнлекләре буенча шулай ук яшьләрнең рухи-әхлакый мәдәни үсешенә ярдәм итә торган яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм

итү өчен камилләшкән шартлар тудырачак.

Алдагы елларда ирешелгән уңай нәтиҗәләргә карамастан, әлеге этапта бүгенге көндә һәм озак вакытлы перспективага яшьләрнең социаль проблемалары гамәлләрен, формаларын, яшь буын белән эшләү ысулларын билгеләүгә игътибарны көчәйтү таләп ителә. Арча районы яшьләрен рухи, әхлакый һәм мәдәни потенциалын үстерү өчен әлеге Программа максатларында күздә тотылган яшьләр сәясәте органнары куллана торган ысулларны яңадан карарга, төзәтмәләр кертергә кирәк.

## II. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның иң беренче максаты - яшьләрнең социаль үсеше белән идарә итү, районның көндәшлеккә сәләтлелеген ныгытуда аларның иҗади потенциалыннан файдалану, яшь буынның яшәеш сыйфатын күтәрүгә уңайлы шартлар тудыру. Яшь буынның эшмәкәрлек активлыгы потенциалын яңача үстерү юлы белән яшьләрнең үсеше өчен шартлар тудыруга ярдәм итү.

Яшьләр иҗтимагый оешмалары төзү, яшьләр оешмалары, хәрәкәтләр һәм яшьләр оешмаларына ярдәм итү кысаларындагы социаль проектлар өчен шартлар тудыру мөһим максат булып тора.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге балалар һәм яшьләрнең фестивальләр, конкурслар, олимпиадалар һәм җәмәгать оешмаларына җәлеп ителгән яшьләрнең чагыштырма күләме күрсәткече, шулай ук яшьләр инфраструктурасының үсеше һәм тотрыклы эшләве күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк.

Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге түбәндәге күрсәткечләр нигезендә бәяләнәчәк:

- социаль әһәмияттәге проектлар һәм программалар конкурсына бирелгән гаризалар саны;

- талантлы яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән конкурсларда катнашучы яшьләр саны;

- балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегендә

катнашучы яшь кешеләрнең гомуми саны арту.

Сәләтле балаларны һәм яшьләрне эзләү, аларга ярдәм итү, аларның акыл һәм иҗади потенциалын үстерү һәм гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру. Әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге башкарма хакимият органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган талантлы яшьләргә ярдәм итү өлкәсендәге проектлар һәм программаларга җәлеп ителгән яшь кешеләрнең өлешен арттыру күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк.

- яшьләр арасында экстремизмны булдырмау эшләре: әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге яшьләр экстремизмын булдырмау чараларына җәлеп ителгән яшь кешеләр саны күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк;

- яшьләр даирәсендә тискәре күренешләрне булдырмау системасын үстерү һәм гамәлгә ашыру: әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге социаль тискәре күренешләрне булдырмауга юнәлдерелгән чараларда катнашучы яшьләргә күрсәтелгән ярдәм күрсәткече нигезендә бәяләнәчәк;

- дәүләт яшьләр сәясәтен мәгълүмати, кадрлар һәм фәнни-методик яктан тәэмин итү: әлеге бурычны хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә әзерләнгән аналитик, методик эшләр кебек күрсәткечләр саны нигезендә бәяләнәчәк.

## III. ПРОГРАММАНЫ ФИНАНС БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ.

Программаны финанслауның гомуми күләме 2020 - 2023 елларда Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән:

2020 ел - 1573,9 мең сум;

2021 ел - 1573,9 мең сум;

2022 ел - 1573,9 мең сум;

2023 ел – 1573,9 мең сум

Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына Арча муниципаль районы бюджеты турында

карары нигезендә төгәлләштереләчәк.

## IV. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУНЫҢ КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘРЕ

Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәсе булып икътисадый, социаль, мәдәни өлкәләрдә конкурентлыкка сәләтле һәм кирәкле компетенцияләргә ия булган Россия яшь буыны тора.

Яшь буында Ватанга мәхәббәт, үзенең гражданлык бурычы һәм конституциячел бурычлары җаваплылыгын аңлауны тәрбияләү.

14-30 яшьтәге гражданнар балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә җәлеп ителгән балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр өлешенең артуы;

-Яшьләрнең гражданлык һәм патриотик дөньяга карашын формалаштыру, аларның социаль һәм иҗади активлыгын арттыру;

- Ихтыярый (волонтерлык) эшчәнлеккә җәлеп ителгән яшьләр санының артуы;

-Яшьләр сәясәте өлкәсендә органнар һәм оешмалар тарафыннан гамәлгә ашырылучы талантлы яшьләргә ярдәм итү проектларында һәм программаларында катнашкан яшь кешеләрнең өлешен яшьләрнең гомуми саныннан 25 % ка кадәр арттыру;

-Хокук бозган һәм җинаять кылган балигъ булмаганнар өлешенең кимүе;

- Яшь эшмәкәрләрнең өлеше арту;

-Яшьләр сәясәте һәм спорт учреждениеләрендә даими нигездә шөгыльләнүче авыр тормыш хәлендә калган балалар, үсмерләр һәм яшьләрнең өлеше арту;

- Яшьләр сәясәте учреждениеләренә даими нигездә йөрүче яшьләр саны арту;

-Җәйге сәламәтләндерү ялының төрле формалары белән колачланган балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр өлешенең 30 % ка кадәр артуы;

-Яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче яшьләргә социаль ярдәм күрсәтү учреждениеләре эшчәнлегенең көчәюе.

**2020-2023 елларга дәүләт яшьләр сәясәтен (ГМП)**

**финанслауны тәэмин итү**

**(мең сумнарда)**

| | Чыгым статьясы исеме | 2020 | 2021 | 2022 | 2023 |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Муниципаль берәмлектә ГМПны финанслау күләме, шул исәптән:** | 1573,9 | 1573,9 | 1573,9 | 1573,9 |
| | **Республика дәрәҗәсендәге чаралар, шул исәптән:** | | | | |
| 1 | «Созвездие-Йолдызлык»ның зона этабы | 142 871,00 | 142 871,00 | 142 871,00 | 142 871,00 |
| 2 | «Созвездие-Йолдызлык»ның ярымфинал этабы | 97 931,00 | 97 931,00 | 97 931,00 | 97 931,00 |
| 3 | «Созвездие-Йолдызлык»ның финал этабы | 22 360,00 | 22 360,00 | 22 360,00 | 22 360,00 |
| 4 | Татарстан Республикасы ирекле янгын сакчыллыгының иң яхшы бүлекчәсенә смотр-конкурс | 2 916,00 | 2 916,00 | 2 916,00 | 2 916,00 |
| 5 | «Алтын Каләм» - «Золотое перо» республика балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр иҗаты фестиваленең сайлап алу этабы | 4 618,00 | 4 618,00 | 4 618,00 | 4 618,00 |
| 6 | Татарча КВН лигасы сезоны | 30 000,00 | 30 000,00 | 30 000,00 | 30 000,00 |
| 7 | »Чиста булачак» яшьләр экологик хәрәкәте активының республика мәктәбендә катнашу | 1 300,00 | 1 300,00 | 1 300,00 | 1 300,00 |
| 8 | ТР СДО Советы утырышында катнашу | 1 367,00 | 1 367,00 | 1 367,00 | 1 367,00 |
| 9 | Яшьләр сәясәте өлкәсендә квалификация күтәрү | 1 668,00 | 1 668,00 | 1 668,00 | 1 668,00 |
| 10 | «Җиңү волонтерлары» йомгаклау форумы | 1 367,00 | 1 367,00 | 1 367,00 | 1 367,00 |
| 11 | «Ел лидеры» республика конкурсы | 1 367,00 | 1 367,00 | 1 367,00 | 1 367,00 |
| 12 | «Социаль әһәмиятле эшчәнлеккә ирекле катнашучыларны җәлеп итү механизмнары» семинар-тренингларында катнашу | 11 970,00 | 11 970,00 | 11 970,00 | 11 970,00 |
| 13 | Байтик актив мәктәбе өчен профиль сменада катнашу | 1 401,00 | 1 401,00 | 1 401,00 | 1 401,00 |
| 14 | «Эко хәрәкәт» акциясе | 77 780,00 | 77 780,00 | 77 780,00 | 77 780,00 |
| 15 | «Авыл яшьләре» спартакиадасы | 319 604,00 | 319 604,00 | 319 604,00 | 319 604,00 |
| 16 | Региональ бүлекләрнең матбугат хезмәтләре округ мәктәбе | 700,00 | 700,0 | 700,00 | 700,00 |
| 17 | Чаралар өчен костюмнар | 70 000,628 | 70 000,628 | 70 000,628 | 70 000,628 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Җирле әһәмияттәге чаралар, шул исәптән:** | | | | | |
| 1 | «Алтын Каләм» - «Золотое перо» балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты район фестивале | 4 750,00 | 4 750,00 | 4 750,00 | 4 750,00 |
| 2 | ВДВ көненә багышланган хәрби-патриотик бәйрәм | 3 900,00 | 3 900,00 | 3 900,00 | 3 900,00 |
| 3 | Яшьләр көненә, Физкультурачылар көненә багышланган «Туплы Тамаш» мәдәни-спорт бәйрәме | 117 500,00 | 117 500,00 | 117 500,00 | 117 500,00 |
| 4 | »Авыл яшьләре» аграр яшьләр берләшмәсе программасын популярлаштыру максатыннан Арча районы яшь комбайнчыларын бүләкләү | 11 460,00 | 11 460,00 | 11 460,00 | 11 460,00 |
| 5 | Яшьләрне волонтерлык эшчәнлегенә җәлеп итү | 130 000,00 | 130 000,00 | 130 000,00 | 130 000,00 |
| 6 | Яшьләр үзидарәсен үстерү (Яшьләр парламенты) | 75 000,00 | 75 000,00 | 75 000,00 | 75 000,00 |
| 7 | Дәүләт кайгыртуына мохтаҗ яшьләрне социальләштерү | 50 000,00 | 50 000,00 | 50 000,00 | 50 000,00 |
| 8 | Социаль яктан имин булмаган яшьләр белән эшләү | 140 000,00 | 140 000,00 | 140 000,00 | 140 000,00 |
| 9 | Халыкара һәм төбәкара яшьләр хезмәттәшлеген үстерү | 91 070,00 | 91 070,00 | 91 070,00 | 91 070,00 |
| 10 | Яшьләрне сәламәт яшәү рәвешенә һәм спорт белән шөгыльләнүгә тарту, яшьләр арасында иминлек культурасын популярлаштыру | 70 000,00 | 70 000,00 | 70 000,00 | 70 000,00 |
| 11 | Яшьләрдә гаилә кыйммәтләрен формалаштыру | 40 000,00 | 40 000,00 | 40 000,00 | 40 000,00 |